# ИКЕ БАШЛЫ ДИЮ

КАТНАШАЛАР:

Гелнәзек[1].
Җеп, Кәркеш, Тасма, Чыбык — Гелнәзекнең бертуганнары.
Кәҗә.
Энә — аларның әнисе.
Дию: Гареп — Диюнең беренче башы. Шәрык — Диюнең икенче башы.
Бик — бай.
Келә — аның хатыны.
Ефәк — аларның кызы.

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### Беренче күренеш

Ишегалды. Сул якта кечкенә генә өй. Ихата киртәләп алынган. Киртәгә берничә чүлмәк эленгән. Җил капка. Ярлылык күзгә бәрелеп тора. Ишегалды уртасында казан асылган. Ул учакта быгырдап утыра. Коточкыч музыка тавышы. Гелнәзек, Кәркеш, Тасма, Җеп котырып бииләр. Дөнья селкенеп тора сыман.

[1] Гелнәзек — автор варианты. Халык авыз иҗатында — Гөлнәзек.

### Гелнәзек

Бие, бие, Гелнәзек,
Учыңны учка бәреп.
Аякларыңны болга,
Егылма тик, егылма.
Их-ма!

### Җеп

Бии дә сикерә Җеп,
Гелнәзектән күңләшеп.
Елан кебек сыгыла,
Егылма тик, егылма.
Их-ма!

### Кәркеш

Сикер дә идәнгә төш —
Яндырып бии Кәркеш.
Биюче хәзер ул да,
Егылма тик, егылма.
Их-ма!

### Тасма

Ас-са, ас-са, ас-са!
Җилферди җилдә Тасма.

### Чыбык

Сикерә тырык-пырык,
Сездән калышмый Чыбык.

Кәҗә керә.

### Кәҗә

Мәкәкә, мәкәкә...
Бу соң нинди мәрәкә?

Җ е п

Әкәмәт!

Г е л н ә з е к

Кәҗә, кәҗә, кәҗәкәй!
Кил монда, кәҗәләнмә.

К ә р к е ш

Кил, бие безнең белән.

К ә җ ә

Сездә бию кайгысы...

Т а с м а

Кәҗә, кәҗә, кәҗәкәй!
Үзе шундый бәләкәй.
Озын сакал үстергән,
Акыл бирергә кергән.

Ч ы б ы к

Үзеңә булсын акыл!

К ә җ ә

Гелнәзек!

Г е л н ә з е к

Нәрсә? Бие!

К ә җ ә

Егылып китәм хәзер.
Мин бик ач. Үләм, үләм!
Юк монда миңа кадер.

Ч ы б ы к

Дөньяда күпме үлән!
Чык та аша, хөрәсән.

К ә р к е ш

Тәмам туйдырды бит бу!
Вәт бәла, вәт тамаша!
Әнә күрше бакчасы —
Кер дә туйганчы аша.

К ә җ ә

Күрше бакчасына керсәм,
Төшәр, димен, дәрәҗә.
Мин бит мондый гына түгел,
Мин әкияти кәҗә!

Г е л н ә з е к

Булсаң соң...
Син кемнән ким?

К ә җ ә

Безнең күрше бик усал,
Мылтыктан атса нишлим?

Җ е п

Кәҗәкәй! Аптырама.
Синдә генәме тамак,
Мин дә менә ябыктым,
Җеп кебек кенә калдым.

К ә җ ә

Иртән эшкә киткәндә,
Әниегез ни әйтте?

Кәркеш

Ни әйтте?

Тасма

Без белмибез.

Чыбык

Йокладык төшкә хәтле.

Кәҗә

Гелнәзек, онытмыңмы?
«Печән алып кайтыгыз,
Кәҗәне ашатыгыз», —
Диде бит. Җеп җөпләде,
Син дә баш селкеп тордың.

Гелнәзек

Борчылма! Әнә әни
Бер казан аш пешереп
Калдырган. Аша, яме!

Барысы бергә

Аша, аша, кәҗәкәй!

Кәҗә

Кәҗәләр аш ашамый!
Үлән бирегез миңа.
Мин хәзер ачтан үләм.
Йә, бирегез кәбестә!

Җеп

Ай-яй нәзберек нәстә!